ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. **Автомобиль юлларының бүленгән полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү, яңадан урнаштыру, аларны эксплуатацияләү**»;

б) 1 өлештә «инженерлык коммуникацияләрен салу, яңадан урнаштыру, күчерү» сүзләрен «инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү, яңадан урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Региональ һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлының бүленгән полосасы чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзегән, реконструкцияләгән, капиталь ремонтлаган очракта, шул исәптән салган, күчергән, яңадан урнаштырган очракта, төзелешкә рөхсәт тиешенчә вәкаләтле орган йә бүленгән полосасы чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү, яңадан урнаштыру планлаштырыла торган автомобиль юлын төзүгә рөхсәт бирергә вәкаләтле аның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениесе, җирле үзидарә органы тарафыннан бирелә.»;

г) 3 өлештә «инженерлык коммуникацияләрен салган, күчергән яисә яңадан урнаштырган очракта» сүзләрен «инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзегән, реконструкцияләгән, капиталь ремонтлаган очракта, шул исәптән салган, күчергән, яңадан урнаштырган очракта,» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 өлештә «инженерлык коммуникацияләрен проектлау, салу, күчерү яисә яңадан урнаштыру» сүзләрен «инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын проектлау, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү, яңадан урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

2) 25 статьяның $4^1$ өлешендә «инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү, яңадан урнаштыру, аларны эксплуатацияләү максатларында» сүзләреннән соң «, шулай ук элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау максатларында, шул исәптән салу, күчерү, яңадан урнаштыру, эксплуатацияләү максатларында,» сүзләрен өстәргә;

3) 26 статьяда:

а) 7 өлештә «юл сервисы объектларын» сүзләреннән соң «, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын» сүзләрен өстәргә;

б) $7^1$ өлештә «юл сервисы объектларын» сүзләреннән соң «, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 30 сентябрь
№ 59-ТРЗ